Җир кишәрлеген яисә капиталь төзелеш объектын файдалануның
шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү проекты буенча
җәмәгатьчелек белән фикер алышулар башлануы турында
ХӘБӘР ИТҮ

Әлеге хәбәр белән кадастр номеры 16:15:180104:481 булган җир кишәрлегеннән «Кибетләр»гә файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында Югары Ослан муниципаль районы Башлыгының 21.04.2026 ел, №45/п карары нигезендә хокукый акт проекты буенча җәмәгатьчелек белән фикер алышулар башлануы турында хәбәр итәбез.

Проектка мәгълүмати материаллар исемлеге: фотоматериаллар

Проект буенча җәмәгать тыңлауларын үткәрү тәртибе һәм вакыты: 2026 елның 29 апреленнән 2026 елның 18 маена кадәр.

Җәмәгатьчелек белән фикер алышулар Россия Федерациясенең шәһәр төзелеше кодексы, 06.10.2003 ел 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законы, Югары Ослан районы муниципаль берәмлегенең Уставы, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль район Советының 04.06.2020 ел № 58-670 карары белән расланган Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль берәмлегендә шәһәр төзелеше өлкәсендәге проект буенча җәмәгать фикер алышуларын, җәмәгатьчелек белән фикер алышуларны оештыру һәм үткәрү турында нигезләмәдә билгеләнгән тәртип нигезендә уздырыла.

Җәмәгатьчелек белән фикер алышуларда катнашучылар саны: кызыксынучы затлар.

Җәмәгатьчелек белән фикер алышулар үткәрелә торган территория: Татарстан Республикасы, Югары Ослан муниципаль районы, Шилангы авыл җирлеге, Шилангы авылы.

Җәмәгатьчелек белән фикер алышуларда карарга тәкъдим ителә торган проектын күрсәтү урыны һәм датасы: 2026 елның 29 апреленнән түбәндәге мәгълүмат стендларында:

- Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты: 422570, Татарстан Республикасы, Югары Ослан районы, Югары Ослан авылы, Чехов урамы, 18 йорт адресы буенча;
- Шилангы авыл җирлеге Башкарма комитеты:
  422577, Татарстан Республикасы, Югары Ослан районы, Шилангы авылы, Октябрь урамы, 53 йорт адресы буенча

Проект экспозициясен уздыру вакыты: 29.04.2026 елдан 18.05.2026 елга кадәр.

Экспозицияләрне карау мөмкин булган көннәр һәм сәгатьләр турында мәгълүмат:
дүш - җомга 09-00 с.тән 16-00 с.кә кадәр

Җәмәгатьчелек белән фикер алышуларда проектлар буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертү тәртибе, вакыты һәм формасы

Проектның 29.04.2026 елдан 18.05.2026 елга кадәрге бөтен чоры дәвамында. Югары Ослан районының http://verhniy-uslon.tatarstan.ru/ сәхифәсендә каралырга тиешле, «Архитектура һәм шәһәр төзелеше» вкладкасында, экспозиция уздыруда, идентификация узган иҗтимагый фикер алышуларда катнашучылар әлеге проектка кагылышлы тәкъдимнәр һәм кисәтүләр кертергә хокуклы:

1) рәсми сайт аша;

2) иҗтимагый фикер алышуларны оештыручы адресына язма рәвештә - даими рәвештә

иҗтимагый фикер алышуларны оештыручы адресына язма рәвештә — даими

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль берәмлегендә шәһәр төзелеше өлкәсендәге проектлар буенча җәмәгать фикер алышуларын яисә гавами тыңлауларны оештыру буенча гамәлдәге комиссиясе (адресы: 422570, Татарстан Республикасы, Югары Ослан авылы, Чехов ур., 18 йорт, тел: 8 (84379) 2-16-59;

3) «Җир кишәрлегеннән яисә капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төрләренә рөхсәт бирү турында» проекты буенча экспозициягә килүчеләрне исәпкә алу журналында язу юлы белән.

Җәмәгать фикер алышуларында каралырга тиешле проект урнаштырылачак рәсми сайт һәм аңа мәгълүмати материаллар, яисә мондый проект һәм аңа мәгълүмати материаллар урнаштырылачак, шулардан файдаланып җәмәгать фикер алышулары үткәреләчәк мәгълүмати системалар турында мәгълүмат: Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында https://pravo.tatarstan.ru һәм Югары Ослан муниципаль районы сайтында: https://verhniy-uslon.tatarstan.ru.

Җәмәгать фикер алышуларында карарга тапшырылган проект урнаштырылачак рәсми сайт турында мәгълүмат һәм аңа мәгълүмат материаллары: Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайты: https://verhniy-uslon.tatarstan.ru.

Белдерүне бастырырга: 22.04.2026 елдан соңга калмыйча

Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында: https://pravo.tatarstan.ru һәм Югары Ослан муниципаль районының «Интернет» челтәрендәге сайтында: https://verhniy-uslon.tatarstan.ru.

Башкарма комитет җитәкчесе А.А. Әхмәтшин